| | |
|---|---|
| **СОВЕТ УТЯШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2023 елның «13» декабре Өтәшкә ав. № 132_

Өтәшкә авыл җирлеге Советының 2021 елның 9 мартындагы № 28 карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Өтәшкә авыл җирлеге Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында (Өтәшкә авыл җирлеге Советының 2021 елның 18 августы № 44, 2021 елның 20 декабре № 53, 2023 елның 6 апрелендәге 105, 2023 елның 23 августындагы 122 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән).

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Өтәшкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Өтәшкә авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Өтәшкә авыл җирлеге Советы депутаты статусы турында 2021 елның 9 мартындагы 28 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә (Өтәшкә авыл җирлеге Советы карарлары белән 2021 елның 18 августындагы №44, 2021 елның 20 декабрендәге № 53, 2023 елның 6 апрелендәге 105, 2023 елның 23 августындагы 122 карарлары белән кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 статьяга түбәндәге эчтәлекле 2.1 өлеш өстәргә:

«2.1. Депутат, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү күрсәтелгәнгә бәйле булмаган тикшерүләр тарафыннан танылса, коррупциягә каршы тору максатында, 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне һәм бурычларны үтәмәү өчен җаваплылыктан азат ителә 2008 елның 25 декабрендәге 273 - ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында»гы Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталының Интернет челтәрендә

(http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Өтәшкә авылы, Нагорная урамы, 99а йорт (җирлек администрациясе бинасы), Өтәшкә авылы, Үзәк урамы, 40а йорты (мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

**Өтәшкә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **А. А. Клопов**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТ УТЯШКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ӨТӘШКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
ИНН 1620001214
ОГРН 1021606753486